# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында**

**1 статья.** «Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасының республика буйсынуындагы районнарында һәм шәһәрләрендә түбәндәге санда суд участоклары төзергә һәм шул ук санда җәмәгать судьялары урыннары булдырырга:

Азнакай районында һәм Азнакай шәһәрендә - 3; Аксубай районында - 2; Актаныш районында - 2; Алексеевск районында - 1; Алабуга районында һәм Алабуга шәһәрендә - 3; Апас районында - 1; Арча районында - 2; Әгерҗе районында - 2; Әлки районында - 1; Әлмәт районында һәм Әлмәт шәһәрендә - 8; Әтнә районында - 1; Балтач районында - 2; Балык Бистәсе районында - 1; Баулы районында һәм Баулы шәһәрендә - 2; Биек Тау районында - 2; Буа районында һәм Буа шәһәрендә - 2; Бөгелмә районында һәм Бөгелмә шәһәрендә - 4; Зәй районында һәм Зәй шәһәрендә - 3; Зеленодол районында һәм Зеленодол шәһәрендә - 8; Казан шәһәрендә - 51; Кайбыч районында - 1; Кама Тамагы районында - 1; Кукмара районында - 2; Лаеш районында - 2; Лениногорск районында һәм Лениногорск шәһәрендә - 4: ; Мамадыш районында - 2; Менделеев районында - 2; Минзәлә районында - 1; Мөслим районында - 1; Нурлат районында һәм Нурлат шәһәрендә - 2; Питрәч районында - 2; Саба районында - 2; Сарман районында - 2; Спас районында - 1; Тәтеш районында - 1; Теләче районында - 1; Тукай районында - 2; Түбән Кама районында һәм Түбән Кама шәһәрендә - 9; Чаллы шәһәрендә - 21; Чирмешән районында - 1; Чистай районында һәм Чистай шәһәрендә - 3; Чүпрәле районында - 1; Югары Ослан районында - 1; Ютазы районында - 1; Яңа Чишмә районында - 1.

**2 статья.** Республика буйсынуындагы районнарның һәм шәһәрләрнең администрация башлыклары әлеге Закон гамәлгә кергән көннән соң бер ай эчендә «Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары турында»

329



Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 4 пункты таләпләре нигезендә суд участокларының чикләрен билгеләргә тиеш.

**3 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 31 мае
№ 177